ПӘНҖЕШӘМБЕ
25
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 46 (6768)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һәм КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һәм ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

## *Пленум карарларын тулысынча тормышка ашыру өчен!*

**Шушы көннәрдә ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы булып үтте. Пленум, 1942 нче авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1943 нче елгы язгы чәчү кампаниясенең бурычлары турындагы, республика колхозларында һәм совхозларында терлекчелекне үстерүнең дәүләт планын үтәүнең йомгаклары турындагы һәм Татарстан партия оешмасы сафларының үсеше турындагы мәсьәләләрне тикшерде һәм алар буенча тиешле карарлар кабул итте.**

**Немец оккупантларына каршы бөек ватан сугышы халык хуҗалыгының барлык тармакларында да кыенлыклар китереп чыгарды. Бу кыенлыклар авыл хуҗалыгы өлкәсендә дә кечкенә түгел, әлбәттә. Бөек юлбашчыбыз кыенлыклардан курыкмаска, ә аларга каршы барырга һәм җиңеп чыгарга, дип өйрәтә. Безнең партиябез әнә шул күрсәтмәдән чыгып эш итә һәм совет кешеләрен шуңа рухландыра. Кыенлыклар бар, ләкин алар җиңелерлек. Моны үткән елгы төп авыл хуҗалыгы эшләренең йомгаклары ачык күрсәтәләр. 1942 нче елгы авыл хуҗалыгы эшләре 1941 нче елгыга караганда шактый дәрәҗәдә оешканрак төстә үтте. Көзге чәчүнең дәүләт планы 109,9 процент итеп үтәлде, терлек азыклары силослау планы арттырып үтәлде, туңга сөрү 1941 нче елга чагыштырганда 273.000 гектарга артыграк үткәрелде.**

**Югарыда китерелгән фактлар безнең тылның какшамас ныклыгы турында, совет кешеләренең теләсә нинди кыенлыкларны да җиңә алулары турында, безнең партия оешмаларыбызның оештыручанлык роле тагын да югарырак күтәрелгәнлеге турында ачык күрсәтәләр. Алар шул ук вакытта безнең халык хуҗалыгы тармакларының, шул исәптән авыл хуҗалыгында, тагын да яхшырак эшләүләре өчен бөтен мөмкинлекләре барлыгын бик ачык күрсәтәләр.**

**Ләкин гомумән алганда исә авыл хуҗалыгына җитәкчелек итүдә әле безнең партия һәм совет оешмаларының эш практикасында җитди кимчелекләр яшәп килә. Алар, барыннан да элек, һәм аеруча 1942 нче елда күп кенә план заданиеләрен үтәмәүдән, язгы чәчүдә, уңауда, пар җирләрен сөрүдә һәм эшкәртүдә, ашлык сугуда, туңга сөрүдә билгеләнгән срокларны өзүдән гыйбарәт булдылар. Өлкә Комитеты пленумы, ашлык һәм башка төрле авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү эшендә күп кенә партия, совет, җир һәм әзерләү органнарының гадәттән тыш начар эшләгәнлекләрен, шуның нәтиҗәсендә бер генә районның да дәүләткә ашлык тапшыру планын үтәмәгәнлекләрен күрсәтеп үтте.**

**Икмәк сугыш припаслары һәм кораллары җитештерүче промышленность эшчеләре өчен кирәк, икмәк безнең сөекле Кызыл Армиябез өчен кирәк. Ашлык тапшыру планын үтәү—ул фронт заказларын үтәү белән бер. Шуңа күрә дә ашлык тапшыру эшләре йомшартылмаска, ә көчәйтелергә, ашлык тапшыру планын 10 нчы марттан да соңга калмыйча үтәү өчен барлык җитди чаралар күрелергә тиеш. Бу, партия, совет оешмаларының, политбүлекләрнең иң мөһим бурычларыннан берсе.**

**1943 нче елның язгы чәчүенә үрнәкле төстә әзерләнү һәм аны бик яхшы сыйфатлы итеп оешкан рәвештә үткәрү—ул республикабыз партия оешмаларының сугышчан бурычы булып тора. 1943 нче елны хәрби уңыш алынырга тиеш! Фронт әнә шуны таләп итә. Партия оешмаларының, җир органнарының бурычы, һичшиксез, югары иген уңышы алуны тәэмин итүдән гыйбарәт. Ә моның өчен язгы чәчүгә барлык тармаклар буенча отлично әзерләнү кирәк. Пленум, агротехника кагыйдәләрен үтәүгә һәм аны өйрәнүгә аеруча зур игътибар бирде. Агротехника чараларын үз вакытында тулысынча үтәү, барлык тракторларга һәм башка авыл хуҗалыгы машиналарына отлично сыйфатлы ремонт ясауны үз вакытында үткәрү, язгы чәчү өчен кирәкле булган чәчү орлыкларын туплау, авыл хуҗалыгы эшләренең барлык төрләре буенча да кадрлар әзерләү—язга әзерлектә иң мөһим чаралар әнә шулар.**

**«ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы барлык партия, комсомол, совет һәм профсоюз оешмаларын — масса арасында политик эшне, колхозларда, МТС ларда һәм совхозларда социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен киң җәелдерергә, партия-комсомол көчләрен хәлиткеч тармакларга урнаштырырга, язгы чәчүгә үрнәк булырлык итеп әзерләнүгә һәм аны үткәрүгә, югары һәм ныклы иген уңышы өчен көрәшкә, Кызыл Армиягә ярдәмне көчәйтүгә барлык колхозчыларны, колхозчы хатын-кызларны, МТС һәм совхоз эшчеләрен, авыл хуҗалыгы белгечләрен тупларга, немец-фашист басып алучыларны тизрәк һәм тәмам тар-мар итү өчен кирәк булган продукцияне фронтка тагын да күбрәк һәм күбрәк бирүне тәэмин итәргә мәҗбүр итә». (IX нчы пленум карарыннан).**

**Фронтка ит, сөт, май кирәк. Бу таләпне үтәүдә безнең республикабыз зур урын тота. 1942 нче елны безнең республикада ит тапшыру планы 104,7 процентка үтәлде. Бу уңышлы факт. Ләкин шуның белән бергә әле терлекчелек өлкәсендә гаять зур кимчелекләр дә яшәп килә. Республика күләмендә тулаем алганда, терлекчелекне үстерүнең дәүләт планы үтәлмәгән булу моны ачык раслый. Партия оешмаларының игътибары терлекчелек өлкәсендә яшәп килгән җитди кимчелекләрне тиз бетерүгә юнәлдерелгән булырга, терлекчелек эшен үз кулларына алырга һәм иң кыска вакыт эчендә җитди уңышларга ирешергә тиешләр.**

**ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы республикада партия сафларының үсеше мәсьәләсенә зур игътибар бирде. Ватан сугышы чорында илебезнең хезмәт ияләре арасында производство һәм политик активлык аеруча югары күтәрелде. Партия оешмалары бу активлыкны тагын да көчәйтергә, аңа җитәкчелек итәргә тиешләр. ВКП(б) райкомнары һәм башлангыч партоешмалар партия сафларын үстерү мәсьәләсе белән көндәлек рәвештә шөгыльләнергә, үзләрен практик эштә таныткан, Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән алдынгы кешеләрне партия сафларына тартырга тиешләр.**

**Пленум партия оешмалары өчен җитди эш программасы бирде. Хәзер бурыч — пленум күрсәтмәләрен тулысынча үтәү өчен большевистик көрәш оештырудан гыйбарәт. ВКП(б) райкомының, аларның пропаганда һәм агитация бүлекләренең бурычы, партия кабинетларының, агитколлективларның, пропагандистларның һәм агитаторларның бурычы пленум карарларын колхозчылар массасына тулысынча җиткерүдән, пленум карарларыннан килеп чыккан бурычларны үтәүгә киң массаны туплаудан гыйбарәт.**

## ГРЕЦИЯ КОРОЛЕ ГЕОРГ II НЕҢ СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ М. И. КАЛИНИНГА ТЕЛЕГРАММАСЫ

Кызыл Армиянең 25 еллыгы, бу кампаниядә аның гүзәл җиңүләре белән бергә туры килгән бу еллык, президент әфәнде, совет армияләренә минем үз соклануымны һәм халкымның соклануын Сезгә белдерергә, аларга тиешле бәяне бирергә һәм агрессорларның котылгысыз рәвештә бәреп төшереләчәкләренә безнең ышанычыбызны белдерергә миңа мөмкинлек бирә.

**ГЕОРГ II.**

ЛОНДОН, 23 февраль, 1943 ел.

## Америка Кушма Штатлары Президенты Франклин Д. Рузвельт әфәнденең СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш И. В. СТАЛИНГА ТЕЛЕГРАММАСЫ

Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән, аның гүзәл, бөтен тарихта моңарчы тиңдәше булмаган казанышларына Кушма Штатлар халкы исеменнән үзебезнең тирән соклануыбызны белдерергә телим. Күп айлар буена материалларны, транспорт средстволарын һәм территорияләрне бик күп югалтуга да карамастан, Кызыл Армия иң куәтле дошманга җиңүгә ирешү мөмкинлеген бирмәде. Ул Ленинград янында, Москва янында, Воронеж янында, Кавказда аны туктатты һәм, ниһаять, мәңге хәтердә калырлык Сталинград сугышында Кызыл Армия дошманны җиңү генә түгел, бәлки бик яхшы һөҗүмгә күчте. Бу һөҗүм Балтикадан алып Кара диңгезгә кадәр булган бөтен фронт буйлап электәгечә уңышлы рәвештә җәелеп бара. Дошманның чигенергә мәҗбүр булуы, кешеләр, материаллар, территорияләр ягыннан аңа бик кыйммәткә төшә һәм бигрәк тә аның мораль хәленә авыр йогынты ясый. Мондый казанышларга бары тик оста җитәкчелеккә, нык оешмага, тиешле әзерлеккә ия булган һәм барыннан да элек, үзенең корбаннарына да карамастан, дошманны җиңүгә карар биргән армия генә ирешә ала.

Шул ук вакытта мин рус халкына тиешле бәяне бирергә телим. Кызыл Армия бу халыктан үзенең чыганакларын ала һәм үзенең ирләрен, хатын-кызларын һәм тәэминат өчен кирәкле булган әйберләрен ала. Рус халкы шулай ук үзенең бөтен көчләрен сугышка бирә һәм зур корбаннар бирә. Кызыл Армия һәм рус халкы, һичшиксез, Гитлерның коралллы көчләрен тәмам җиңелүгә таба барырга мәҗбүр иттеләр һәм озак вакытларга кадәр Кушма Штатлар халкының соклануын яулап алдылар.

**ФРАНКЛИН Д. РУЗВЕЛЬТ.**

ВАШИНГТОН, 22 февраль, 1943 ел.

## СССР ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ И. В. СТАЛИННЫҢ АМЕРИКА КУШМА ШТАТЛАРЫ ПРЕЗИДЕНТЫ ФРАНКЛИН Д. РУЗВЕЛЬТКА ТЕЛЕГРАММАСЫ

Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән Сезнең дусларча мөрәҗәгатегез өчен һәм аның сугыштагы уңышларына югары бәя биргәнегез өчен Сездән минем чын күңелдән рәхмәтемне кабул итүегезне үтенәм.

Бу уңышлар безнең гомуми дошманыбызны тәмам җиңү юлын ачарлар дигән Сезнең ышанычыгызга кушылам. Бу дошман безнең илләребезнең һәм азатлык сөюче барлык халыкларның берләшкән куәте белән җимерелергә, тиеш һәм җимерелер.

**И. СТАЛИН.**

## ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе Гали җәнаб И. В. СТАЛИН әфәндегә

Соңгы атналар эчендә Сезнең илегезнең армияләре күп кенә атаклы шәһәрләрне бер-бер артлы алдылар һәм талаучы дошманнарны себереп түктеләр. Шуның белән Сезнең армияләрегез күчәр державаларының юлбасар бандаларын тулысынча тар-мар итүне алдан ук хәл иттеләр һәм берләшкән милләтләрнең тизләтелгән каршы һөҗүме бик вакытлы икәнлекне тагын да яхшырак расладылар. Сугыштагы бу гаять гүзәл казанышларга без Сезнең акыллы һәм зирәк җитәкчелегегездә илегезнең армияләренең һәм халкыгызның герсик көрәшенә бөтенләй бурычлыбыз. Сезнең җиңүләрегез турындагы хәбәрләргә мин чиксез шатланам.

Советлар Союзы Кызыл Армиясенең 25 еллыгы көненә мин Кытайның барлык армиясе һәм барлык халкы белән берлектә Сезгә чын күңелдән котлавымны җибәрәм. Җиңү гимнының тавышлары Сезгә килеп торудан туктамасын!

Көнчыгышта да, көнбатышта да күчәр илләрнең кораллы көчләрен юк итү бөтен дөньяда тулысынча ныклы тынычлык урнаштыруга кирәкле шарт булганлыктан, берләшкән милләтләрнең язмышлары тулысынча бергә бәйләнгән һәм бер илнең җиңүе бөтенебез өчен җиңү булып тора. Кытай һәм Советлар Союзы, бер корабльдә булган кешеләрнең иптәшлек рухы белән сугарылган хәлдә, бергә хәрәкәт итеп һәм үзара ярдәм күрсәтеп, бөтен дөньяда гадел солыхка мөмкин кадәр тизрәк нигез салу өчен барлык көчләрен бирергә тиешләр.

**ЧАН КАЙ-ШИ.**

ЧУНЦИН, 20 февраль, 1943 ел.

## СССР ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ И. В. СТАЛИННЫҢ ГЕНЕРАЛИССИМУС ЧАН КАЙ-ШИГА ТЕЛЕГРАММАСЫ

Кызыл Армиянең 25 еллыгы һәм гитлерчы басып алучыларга каршы көрәштә аның уңышлары уңае белән Сезнең дусларча котлавыгыз өчен минем чын күңелдән рәхмәтемне кабул итүегезне үтенәм.

Сезгә һәм Сезнең аркылы кытай халкына иң яхшы теләкләремне һәм чын күңелдән котлауларымны җибәрәм.

**И. СТАЛИН.**



**ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ.** (Ленинград фронты). Вологда өлкәсе урманнарында Битюковлар бригадасының иң яхшы стахановчы бригадаларның берсе иде. Сугыш башлангач 5 туган—Александр, Георгий, Иван, Николай һәм Василий Битюковлар бер частька туры килделәр. Аларны бер батареяга билгеләделәр. Агач кисүче мастерлар артиллерия уты мастерлары булып әверелделәр. Күптән түгел Битюковлар, туры атып, фашистларның бер корылмасын җимерделәр һәм шул вакытта 30 га якын гитлерчыларны кырдылар.

Рәсемдә: Битюковлар расчеты ут позициясендә. Сулдан уңга — замковый Василий, новодчик Николай, установщик Александр, правильный Георгий һәм коручы Иван.

Коновалов фотосы (ТАСС).

# СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

## 24 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

24 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть сугышчылары, су чиге аркылы кичеп, күп кенә уңайлы биеклекләрне алдылар һәм немецларның бер ротага якын пехотасын юк иттеләр. Немецлар, безнең гаскәрләрнең алга баруын тоткарларга маташып, сугышка бик күп авиация керттеләр. Совет истребительләре һәм зенитчиклары җир өсте гаскәрләренә булышалар һәм дошман самолетларын юк итәләр. Һава сугышларында һәм аэродромнарда кичә немецларның 35 самолеты юк ителде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар алга таба барып, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер группа совет танкистлары немецларның 6 орудиесен, 10 автомашинасын юк иттеләр һәм 200 дән артык гитлерчыларны кырдылар.

* * *

Красноармейское районында Н-че часть позицияләренә каршы контратакага немецлар 30 танк җибәргәннәр иде. Безнең артиллеристлар аларга каршы ут ачтылар һәм туры атып дошманның 7 танкысын юк иттеләр. Шуның өстенә немецларның 4 танкысын безнең бронебойщикларыбыз сафтан чыгарды. Гитлерчылар, сугыш кырында зарарланган һәм яндырылган 11 танкларын калдырып, ашыгыч рәвештә элекке позицияләренә чигенделәр.

* * *

Украинада безнең гаскәрләр Лебедин шәһәрен алганнан соң тагын да алга киттеләр. Совет танкистлары һәм моторлаштырылган пехота, халык яши торган бер пункт өчен булган сугышта 300 гә якын гитлерчыны кырдылар. Шулар арасында танкка каршы ата торган 8 орудие, 37 автомашина, зур сугыш припаслары склады һәм бер корал склады бар. Икенче бер участокта безнең сугышчылар омтылышлы атака белән дошманның көчле итеп ныгытылган бер терәк пунктын алдылар.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр немецлар оборонасының ныгытылган линиясен җимереп, су чиге аша кичтеләр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. 600 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең сугышчылар немецларның 462 нче полкының 9 нчы һәм 10 нчы роталарын, шулай ук 90 кешедән торган унтер-офицерлардан гына төзелгән махсус отрядын кырып бетерделәр.

* * *

Ровно өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары Германиядән килеп урнашкан бер алпавытның имениесен туздырганнар. Хуҗалык каралтылары, авыл хуҗалыгы инвентаре һәм ашлык складлары яндырылган. Икенче көнне партизаннар дошманның бер тимер юл эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә һәм тимер юл сакчылары белән булган атышта 100 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары үтерелгән.

* * *

Ворошиловград өлкәсенең хәзер азат ителгән Киминово авылында торучылар немец-фашист оккупантларның совет гражданнарын Германиягә ирексезләп озатулары турында акт төзеделәр. Актта болай диелә: «1942 нче елның сентябрь һәм октябрь айларында немец-фашист кабахәтләр безнең авылдан 95 колхозчыны — ирләрне һәм хатын-кызларны — Германиягә каторгага куып алып киттеләр. Гитлерчылар ирләрне һәм хатын-кызларны кимсетүле медицина каравыннан үткәрделәр. Кол биләүче немецлар үзләре яраклы дип тапкан барлык кешеләрне 60 километр ераклыктагы бүлү пунктына җәяүләп озаттылар. Бандитлар аналарны балаларыннан аердылар. Станциядә гитлерчылар хәлдән тайган һәм кайгыхәсрәткә чумган кешеләрне товар вагоннарына этеп-төртеп керттеләр, аларны бикләп куйдылар һәм Германиягә каторга эшенә алып киттеләр.

Немец-фашист басып алучылар эшләгән җинаятьләрне без беркайчан да онытмабыз. Үзебезнең бөтен көчебезне һәм барлык средстволарыбызны Кызыл Армияне ныгытуга бирербез. Барлык совет кешеләрен фашистлар коллыгыннан мөмкин кадәр тизрәк азат итү өчен Кызыл Армия белән берлектә көрәшеп гитлерчыларны юк итәрбез».

* * *

Югославиядә партизаннар белән немец-итальян гаскәрләре арасында бик каты сугышлар дәвам итә. Партизаннар, соңгы сугышларда оккупантларның атакаларын кире кайтарып, дошманның 8 танкысын юк иткәннәр, 1.000 нән артык немец һәм итальян солдатларын һәм офицерларын кырганнар. Партизаннар кулына төшкән трофейлар арасында 3 төзек танк бар. Гори Лапац шәһәре янында булган сугышларда партизаннар итальяннарның бер рота пехотасын кырып ташлаганнар, бер танкысын, сугыш припаслары төялгән 4 автомашинасын юк иткәннәр. 4 миномет, 8 пулемет, 100 винтовка һәм 30 мең патрон кулга төшерелгән.

# ВЛКСМ НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ VII нче ПЛЕНУМЫ

20-21 нче февральдә ВЛКСМ Татарстан Өлкә Комитетының VII нче пленумы булып үтте. Пленум түбәндәге мәсьәләләрне тикшерде: 1. 1943 нче елгы язгы чәчү кампаниясенә әзерлек һәм аны үткәрүдә Татарстан комсомол оешмасының бурычлары турында; 2. «Пионер оешмаларының эшендәге зур җитешсезлекләр һәм бу җитешсезлекләрне төзәтү чаралары турында» ВЛКСМ Үзәк Комитетының 1942 нче ел, 15 нче сентябрь карарының Татарстан комсомол оешмалары тарафыннан үтәлүенең барышы турында.

Беренче мәсьәлә буенча ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш **Пазиков** доклад ясады.

Докладчы ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленум карарларына җентекләп тукталды. Иптәш Пазиков болай диде:

—ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы авыл хуҗалыгы өлкәсендә партия оешмаларының начар эшләүләренең төп сәбәпләрен ачып салды. Авыл хуҗалыгы эшләренең планы өзелүдә һәм ашлык әзерләү заданиеләренең үтәлмәвендә, 1943 нче елгы язгы чәчү кампаниясенә начар әзерләнүдә шулай ук комсомол да җаваплы.

Докладчы, комсомол оешмаларының колхоз производствосыннан читтә торучы, комсомолецларның эшләре белән кызыксынмаучы һәм аларны югары иген уңышы өчен көрәшкә тупламаучы комсомол җитәкчеләрен тәнкыйть итте. Кама Тамагы, Лаеш, Кузнечиха һәм башка күп кенә районнарның күпчелек комсомол оешмалары язгы чәчү кампаниясенә әзерлек эшенә аз катнашалар.

Иптәш Пазиков, авылда комсомол оешмаларының эшен яхшырту буенча үткәрелергә тиешле конкрет чаралар турында сөйли. Язгы чәчүгә әзерлектә һәм аны үткәрүдә актив катнашу, югары иген уңышы өчен көрәштә инициатор булу — комсомол оешмаларының изге бурычы. Һәрбер комсомолец югары иген уңышын яулап алуда алдынгы көрәшче булырга тиеш.

Москва өлкәсе яшьләренең чакыруы Татарстан яшьләре арасында ныклап тикшерелергә тиеш. Комсомол оешмалары 1943 нче елның хәрби язын үрнәкле итеп үткәрүгә барлык яшьләрне, барлык колхозчыларны һәм колхозчы хатын-кызларны тупларга тиешләр.

Доклад буенча фикер алышуларда беренче булып ВЛКСМ ның Мамадыш райкомы секретаре иптәш Гыйсмәтуллина сөйләде. Ул, райондагы комсомол оешмаларының язгы чәчүгә әзерлек эшендә колхозларга, МТС ларга һәм совхозларга ничек ярдәм итүләрен сөйли. Ләкин бу ярдәм әле җитәрлек түгел. Күп кенә колхозларда комсомолецлар җитешсезлекләрне теркәү белән генә чикләнәләр. Производствода авангардлык өчен көрәшмиләр.

ВЛКСМ ның Октябрь райкомы секретаре иптәш **Насирова** югары иген уңышы өчен көрәшкә үзләренең бөтен көчләрен биреп эшләүче стахановчы яшь колхозчылар турында сөйләде. Председателе комсомолец иптәш Краснов булган «Ерепкино» колхозы урып-җыю һәм дәүләткә ашлык тапшыру эшләрен районда беренче булып тәгәлләде. Районның комсомолецлары язгы чәчүгә тырышып әзерләнәләр.

ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире иптәш **Перов**, күп кенә районнардагы комсомол оешмаларының югары иген уңышы өчен көрәштә партия оешмаларына ярдәм итүләре йомшак булуны тәнкыйтьләде. Ул болай диде:

—Комсомол оешмаларында әле агротехниканың файдасы турында күп сөйләргә ярата торган, ә эштә аны үткәрүгә яшьләрне оештырмый торган кешеләр дә бар. Барлык комсомолецлар, барлык яшьләр хәзер агротехника белән җитди рәвештә шөгыльләнергә тиешләр.

ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре иптәш **Луцкер** комсомол оешмаларының оештыру-политик эшләре турындагы мәсьәләгә тукталды. Ул, республиканың районнарындагы күп кенә колхозларда һәм совхозларда комсомол оешмалары булмавын әйтеп үтте. Комсомолның күп кенә райкомнары ВЛКСМ сафларына яңа членнар кабул итү, колхозларда һәм совхозларда комсомолның башлангыч оешмаларын оештыру буенча канәгатьләнерлек эшләмәүләрен тәнкыйтьләде.

Мәсәлән, Аксубай районында IV кварталда бары 12 кеше генә кабул ителгән. Алабуга районында да комсомол сафларының үсеше начар тора. Анда 85 колхозның бары 25 endә генә комсомол оешмасы бар. Якындагы вакыт эчендә барлык колхозларда да башлангыч комсомол оешмасы булуга ирешергә кирәк.

Пленумда кабул ителгән карар буенча ВЛКСМ Өлкә Комитеты бюросы, шәһәр һәм район комитетлары, МТС лардагы һәм совхозлардагы политбүлек начальникларының комсомол эше буенча ярдәмчеләре һәм ВЛКСМ ның башлангыч оешмалары — колхозлардагы һәм район үзәкләрендәге комсомолецларның иң зур күпчелегенең турыдан-туры язгы чәчү эшләрендә чәчүче, сабанчы, тырмачы һ. б. булып эшләүләренә ирешергә тиешләр. Комсомол оешмалары һәрбер колхоз һәм совхоз өчен агротехника чаралары планының һичсүзсез үтәлүенә ирешергә тиешләр. Язгы чәчү эшләре башланганчы һәрбер комсомолец кимендә 50 килограмм көл, 20 килограмм кош тизәге җыярга, колхозчыларның, эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең ишек алларыннан 15 йөк тирес чыгарырга һәм бер-ике гектар мәйданда кар сулары тотарга тиеш.

Пленум һәрбер колхоз комсомол оешмасы янында чәчү орлыклары салу һәм тазарту буенча комсомолецлардан, яшь колхозчылардан һәм совхоз эшчеләреннән звенолар төзергә карар бирде. Комсомолецлар һәм пионерлар көче белән чәчү орлыкларының төгәл учетын алып баруга һәм аның саклануына көндәлек контроль булдырырга кирәк. Орлыкларның язгы чәчүгә әзерлеген тикшерү буенча 1943 нче елның 10 нчы мартыннан алып 1 нче апреленә кадәр ике декадник үткәрергә. Комсомолецлар, яшьләр, пионерлар һәм мәктәп балалары көче белән бәрәңге кисентеләре җыюны көчәйтергә кирәк.

Пленум, комсомол оешмаларын тракторларга тагылма һәм заправка инвентарен ремонтны кичекмәстән тәгәлләү өчен чаралар күрергә мәҗбүр итте. Җанлы тарту көчләрен әзерләү эшенә гаять зур әһәмият биреп, пленум, ВЛКСМ райкомнарын һәм башлангыч оешмаларны атларны язгы кыр эшләренә әзерләүдә актив катнашырга мәҗбүр итте.

* * *

Көн тәртибендәге икенче мәсьәлә буенча Өлкә Комитетының мәктәпләр буенча секретаре иптәш Абдуллин доклад ясады.

Бу мәсьәлә буенча кабул ителгән карарда пленум, ВЛКСМ райкомнарыннан, шәһәр комитетларыннан һәм ВЛКСМ Өлкә Комитеты бюросыннан пионер оешмаларының эшенә җитди игътибар бирүне, ВЛКСМ Үзәк Комитеты тарафыннан билгеләнгән барлык чараларны төгәл үтәүне таләп итте. Бу резолюциядә ВЛКСМ Үзәк Комитетының 1942 нче ел, 15 нче сентябрь карарын үтәүне тәэмин итә алырлык күп кенә практик чаралар билгеләнде.

* * *

Пленум шулай ук оештыру мәсьәләләрен дә тикшерде. Пленум иптәш Б. М. Луцкерны ВЛКСМ Өлкә Комитетының беренче секретаре итеп сайлады, аны ВЛКСМ Өлкә Комитеты пленум составына кертте һәм ВЛКСМ бюросы члены итеп сайлады. Пленум иптәш М. Х. Шәфиковны ВЛКСМ Өлкә Комитетының икенче секретаре итеп сайлады. ВЛКСМ ның Казан шәһәр комитеты секретаре иптәш Б. Д. Изюмов ВЛКСМ Өлкә Комитетының пленумы һәм бюросы членлыгына кертелде. Иптәш М. Б. Юскаева ВЛКСМ Өлкә Комитетының пропаганда буенча секретаре итеп, иптәш И. В. Заикин хәрби эш буенча секретарь итеп сайландылар. Иптәш Р. Х. Усманова крестьян яшьләре бүлеге мөдире итеп расланды.

# КЫЗЫЛАРМЕЕЦ СЕМЬЯЛАРЫНА ЯРДӘМ

Шәһәрнең Бауман районында Кызыл Армия сугышчыларының һәм командирларының семьяларына ярдәм күрсәтү буенча күп кенә чаралар үткәрелә. Мондый семьяларның материаль-көнкүреш хәлләрен тикшерү эшләре алып барыла. Мохтаҗ булганнар утын һәм промышленность товарлары белән тәэмин ителәләр. Соңгы декадада 767 семьяга материаль ярдәм күрсәтелде. Аларга 410 кубометр утын, 399 данә төрле киемнәр, 270 балага күн аяк киемнәре, 350 пар хатын-кыз туфлялары һәм 4.500 сум акча бирелде.

# Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказына хезмәт фронтында яңа җиңүләр белән җавап бирик!

## ФРОНТ ЗАКАЗЛАРЫН СРОГЫННАН ЭЛЕК ҮТӘҮ ӨЧЕН

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның 23 нче февраль приказы баш инженеры иптәш Корнеев булган заводның эшчеләре, инженер-техник работниклары һәм хезмәткәрләре арасында зур шатлык һәм ватан өчен, героик Кызыл Армия өчен тагын да тирәнрәк горурлык тудырды. Приказ уңае белән хезмәт энтузиазмы яңа, көчле дулкын булып кузгалды. Һәркайда да зур күтәренкелек белән митинглар үтә.

Начальнигы иптәш Волков булган цехта үткәрелгән митингта стахановчы иптәш Сурков чыгыш ясап, түбәндәгеләрне әйтте:

— Стахановчылар һәм барлык совет халкы Кызыл Армиягә, аның батыр улларына, уңышлы һөҗүмне дәвам иттерүләре, дошманны тар-мар итүләре өчен рәхмәт белдерәләр. Верховный Баш Командующий иптәш Сталинга без үзебезнең ялкынлы сәламебезне җибәрәбез. Батыр Кызыл Армиябез өчен сугыш коралларын күбрәк һәм күбрәк бирү өчен мин барлык коллективны тагын да күп тапкыр арттырылган энергия белән эшләргә чакырам. Мин үзем, иптәш Сталинның приказына җавап итеп, нормаларны һәркөнне 270 процентка үтәп барырга сүз бирәм.

## КЫЗЫЛ АРМИЯГӘ БҮЛӘКЛӘР

Кызыл Армиябезнең данлыклы XXV еллыгы уңае белән Биектау районының «Урал» колхозы членнары гомуми җыелыш үткәрделәр. Колхозчылар үз хуҗалыкларындагы запаслардан Кызыл Армия өчен, һәр хезмәт көненә тия торган ашлыктан кимендә 125 әр килограмм исәбеннән, ашлык тапшырырга карар бирделәр.

Карар тормышка ашырыла. 19 нчы февральдә колхоз председателе иптәш Насыйбуллин һәм колхозчы Ибрай иптәш Галимовлар унар пот, Хәлимә иптәш Зиннәтуллина 137 килограмм, Галиябану иптәш Вәлиуллина 147 килограмм ашлык тапшырдылар. Колхозчылар тик бер көн эчендә генә дә Кызыл Армия фондына 20 центнер ашлык бүләк иттеләр.

**С. ДИМИТРОВ.**

## МЕТАЛЛИСТЛАРНЫҢ УҢЫШЛАРЫ

Партоешма секретаре урынбасары иптәш Закиров булган Н-че заводның ремонт-механика мастерскойларында эшләүче металлистлар, данлыклы Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган ярышта яңа җиңүләргә ирештеләр һәм бәйрәмне алар үз өсләренә алган йөкләмәләрен үтәү белән каршыладылар.

Механика цехында эшләүче иптәш Сунцев бригадасы (мастеры иптәш Щеголев булган сменада) ярыш чорында заданиеләрне системалы рәвештә 140—185 процент үтәп килде. Кайбер аерым көннәрдә бу бригада нормаларны 200 процентка үтәде.

Цехтагы аерым эшчеләрдән—токарь П. Матвеев, Г. Козлов иптәшләр эш нормаларын һәркөн саен 120—190 процентка кадәр үтиләр. Строгаль иптәш Хәкимова норманы 150—210 процент итеп үти.

Тәҗрибәле карт токарьлардан яшьләр дә калышмыйлар. Мәсәлән, өйрәнчек яшь токарьлардан Жуков һәм Леонов иптәшләр заданиене 110—172 процентка кадәр үтиләр. Эшләренең сыйфаты яхшы.

Бу цехның, шулай ук, мастеры иптәш Цыганок булган сменасы да ярышта кушылып алган йөкләмәләрен намус белән үтәде. Токарь Курцев Борис үз нормасын һәркөн саен бер ярым — ике мәртәбә арттырып үтәп килде. Токарь Сергей Матвеев та анардан калышмый, планны 150—270 процентка үти. Бу сменада орденлы фрезеровщик иптәш Николаев үзенең улы Александр белән ярышып эшли. Алар икесе дә заданиене 150—200 процентка үтиләр.

Завод металлистлары Кызыл Армиянең 25 еллыгы бәйрәмен әнә шундый уңышлы эш күрсәткечләре белән билгеләп үттеләр.

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказы коллективны яңа җиңүләргә рухландыра.

**М. ГУМЕРОВ.**

## СВОДКА

### ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче ЕЛНЫҢ 20 нче ФЕВРАЛЕНӘ
(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

| МТС лар | Үтәлеш | МТС лар | Үтәлеш | МТС лар | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Мөслим | 100,0 | 38. Кузайкино | 70,9 | 75. Константиновка | 53,8 |
| 2. Чокалы | 100,0 | 39. Акташ | 70,7 | 76. Алексеевский | 52,2 |
| 3. Актаныш | 100,0 | 40. Б. Матак | 70,6 | 77. Морт | 51,0 |
| 4. Бөгелмә | 100,0 | 41. Т. Тамак | 69,2 | 78. Иске Чишмә | 50,0 |
| 5. Нөркәй | 100,0 | 42. Кукмара | 67,9 | 79. Кама тамагы | 50,0 |
| 6. Алга | 100,0 | 43. Балтач | 67,3 | 80. Биләр | 49,2 |
| 7. Тымытык | 100,0 | 44. Әлмәт | 66,7 | 81. Карамалы | 49,1 |
| 9. Тирсә | 100,0 | 45. Тәтеш | 66,7 | 82. Әхмәт | 49,0 |
| 8. Алабуга | 100,0 | 46. Кызыл Чапчак | 66,1 | 83. Казанбаш | 48,5 |
| 10. Ишеево | 100,0 | 47. Яңа Чишмә | 64,7 | 84. Майдан | 48,3 |
| 11. Саба | 96,0 | 48. Бондюг | 64,4 | 85. Питрәч | 46,8 |
| 12. Дөбьяз | 95,8 | 49. Каргалы | 63,3 | 86. Арча | 46,5 |
| 13. Чүпрәле | 95,3 | 50. Баулы | 63,0 | 87. Балык бистәсе | 46,0 |
| 14. Яниль | 88,6 | 51. Беренче Май | 62,7 | 88. Макыл | 45,3 |
| 15. Дәүләки | 87,0 | 52. Рождественский | 62,5 | 89. Черемуховский | 44,4 |
| 16. Сарман | 86,8 | 53. Чалпы | 62,2 | 90. Кызыл юл | 44,4 |
| 17. Кадряк | 86,5 | 54. Маткавыш | 62,1 | 91. Минзәлә | 43,5 |
| 18. Юртыш | 85,7 | 55. Әтнә | 62,0 | 92. Тат. Ялтан | 42,4 |
| 19. Мөрәле | 83,0 | 56. Кичү | 61,9 | 93. Чистай | 41,2 |
| 20. Азин | 81,0 | 57. Теләче | 61,2 | 94. Мамадыш | 40,3 |
| 21. Зөя | 81,0 | 58. Кәкре елга | 60,7 | 95. Чишмә | 39,4 |
| 22. Тархан | 80,3 | 59. Шөгер | 60,4 | 96. Иске Писмән | 38,3 |
| 23. Чүрибураш | 78,7 | 60. Ютазы | 60,0 | 97. Үзәк | 38,2 |
| 24. Чыбыклы | 77,8 | 61. Калинин | 60,0 | 98. Тат. Ходяш | 37,5 |
| 25. Заинский | 77,6 | 62. Исәнбай | 59,5 | 99. Чиябаш | 36,5 |
| 26. Димитров | 77,1 | 63. Әлши | 59,5 | 100. Кузнечиха | 34,9 |
| 27. Соколка | 76,5 | 64. Тельман | 59,0 | 101. Кюлчи | 34,5 |
| 28. Норлат | 76,2 | 65. Мөслим (Чистай) | 58,8 | 102. Трехозерский | 34,0 |
| 29. Октябрь | 75,9 | 66. Зирекле | 57,7 | 103. Биектау | 31,2 |
| 30. Аксубай | 75,0 | 67. Ромодан | 57,4 | 104. Әлки | 30,4 |
| 31. Чаллы | 74,5 | 68. Буа | 57,4 | 105. Кошкино | 28,3 |
| 32. Иске Тимошкино | 73,7 | 69. Столбище | 57,4 | 106. Зур Поляна | 28,1 |
| 33. Юдино | 73,3 | 70. Солтан | 55,9 | | |
| 34. Поповка | 73,2 | 71. Салман | 55,3 | БАРЛЫГЫ: | 63,4 |
| 35. Кызыл йолдыз | 72,2 | 72. Тәкәнеш | 54,7 | 1943 нче елның 15 нче февраленә | 60,3 |
| 36. Олы Кариле | 72,0 | 73. Буденный | 54,4 | | |
| 37. Мәлки | 72,0 | 74. Куйбышев | 54,4 | | |

## ФИНАНС ОРГАННАРЫНЫҢ СУГЫШЧАН БУРЫЧЛАРЫ

Кызыл Армиябез үзенең XXV еллык юбилеен ватан сугышы фронтларында гаять зур уңышлар белән каршылады. Илебезнең бик күп шәһәрләре һәм авыллары немец оккупантлардан азат ителде. Дошманны тәмам тар-мар итү һәм кырып бетерү өчен уңышлы һөҗүмнәр дәвам итә.

Бу бурычны тулысынча хәл итүгә ирешү, дошманны тулысынча җиңү бәйрәмен тизләтү өчен безнең хөкүмәтебезгә бик күп материаль һәм финанс ресурслары кирәк.

Шуңа күрә хәзер финанс эшенең әһәмияте тагын да арта, финанс органнарының җаваплылыгы тагын да зурая.

Татарстан финанс органнары, хезмәт ияләренең гаять көчле патриотик күтәренкелегенә таянып, партия һәм совет оешмаларының актив ярдәме белән, 1942 нче ел финанс программасын уңышлы итеп үтәделәр.

Узган ел эчендә халыктан 1 миллиард сумнан артык акча тупланды. Бу 1941 нче елгы нәтиҗәләргә караганда өч тапкыр күбрәк. Башка төрле доход чыганаклары буенча да шактый уңышларга ирешелде.

Гомумән алганда, безнең республикабыз 1942 нче ел финанс программасын үтәү буенча бөтен Союз күләмендәге социалистик ярыш алдынгылары сафында барды.

Без ирешелгән уңышлар белән тынычланып кала алмыйбыз. Финанс эшен, халык хуҗалыгының барлык тармакларындагы эшләр кебек үк көннән-көн яхшырта барырга, яңадан-яңа уңышларга ирешергә кирәк.

Ләкин, кайбер районнарда бу мөһим бурычны тиешенчә аңлап җиткермиләр. Мәсәлән, Ширәмәт районы (финанс бүлеге мөдире иптәш Клешер). шушы елның беренче квартал планын бары тик 20 процентка гына үтәгән. Анда финанс работниклары арасында социалистик ярыш оештырылмаган, финанс йөкләмәләрен үз вакытында һәм срогыннан элек үтәүнең әһәмиятен халыкка аңлату эше җәелдерелмәгән.

1942 нче елда яхшы эш үрнәкләре күрсәтеп килгән Тымытык, Бондюг, Кама тамагы районнары да бу елның беренче кварталында акча туплау темпын шактый йомшарттылар.

Ватан сугышы вакытында, бигрәк тә Кызыл Армиябез көннән-көн яңа җиңүләргә ирешә барган чакта, тылда эшне йомшарту фактлары хурлыклы гына түгел, бәлки бик зур җинаять. Мондый гамьсезлек һәм җавапсызлык күренешләренә кискен рәвештә чик куярга, барлык чыганаклар буенча да акча туплау планын һәрбер районда, шәһәрдә һәм авылда срогыннан алда арттырып үтәүгә ирешергә кирәк.

1943 нче елны совет халкы илебезнең финанс куәтен ныгыту юлында активлыкны чиксез зур югарылыкка күтәрү белән башлады. Танк колонналары һәм самолет эскадрильялары төзүгә хезмәт ияләре үз инициативалары белән миллионнарча сум средстволар җыеп бирделәр.

Безнең Татарстан хезмәт ияләре, һәр вакыттагы кебек үк, бу эштә дә совет патриотларының алдынгы сафларында булдылар. Республикабыз буенча танк колонналары һәм самолет эскадрильялары төзүгә 185 миллион сумнан артыграк акча җыелды.

Менә шушы акча туплау өчен гаять уңайлы шартларда кайбер финанс органнарының үзләренә йөкләнгән бурычларын үтәмәүләре белән һич тә килешеп булмый. Безнең республикабыз финанс эшенең барлык участоклары буенча да социалистик ярышта алдынгылыкны яулап алырга тиеш. Моның өчен мөмкинлекләр житәрлек.

Хәзер финанс органнарының иң зур бурычы 1943 нче ел өчен авыл халкыннан хәрби налогны якындагы берничә көн эчендә тулысынча җыеп алудан гыйбарәт.

Шуның белән бергә, башка төрле чыганаклар буенча да халыктан җыела торган средстволарны, бигрәк тә ирекле түләүләр суммасын дәүләт тарафыннан билгеләнгән план күләмендә генә түгел, бәлки арттырып үтәүгә ирешергә кирәк. Хәзер бу бурычны үтәү юлында Чепья, Дөбьяз, Кызыл юл, Арча, Апас һ. б. районнар яхшы эш үрнәкләре күрсәтәләр. Бу алдынгы районнар ай ярым эчендә 1943 нче елның беренче квартал планын 115—165 процентка үтәделәр. Эш һәр җирдә дә шулай оештырылырга тиеш.

Доходларны туплау планын үтәү белән бергә, финанс органнары халыкка хезмәт күрсәтү эшен житди рәвештә яхшыртырга тиешләр. Налоглар һәм страхование мәсьәләләре буенча белешмәләр бирү, отыш таблицалары буенча заем облигацияләренә һәм лотерея билетларына чыккан отышларны тикшерү эше—һәрбер финанс работнигының игътибар үзәгендә торырга тиеш.

Финанс органнары һәм сәклык кассалары тарафыннан халыкка хезмәт күрсәтүнең яхшыруы средстволар туплауга, бигрәк тә, заем, вклад, лотерея кебек ирекле түләүләр буенча тагын да күбрәк суммалар җыярга ярдәм итәчәк.

1943 нче елда без дәүләт доходлары буенча да эшнең сыйфатын яңа югарылыкка күтәрергә тиешбез. Социалистик хуҗалыкның мая туплануын арттыру чарасын күрү, һәрбер предприятиенең бюджет алдында булган йөкләмәләрен вакытында һәм тулысынча үтәвен тәэмин итү—финанс органнарының иң изге бурычлары.

Барлык чыганаклар буенча да доход планнарын срогыннан алда һәм арттырып үтәү белән бергә, экономия режимы өчен көрәшне көчәйтергә, дәүләт средстволарының һәр җирдә лә зур саклык белән тотылуына каты контроль оештырырга кирәк.

Узган елда безнең республикабыз буенча төрле оешмаларда шактый акчаны урынсыз тоту һәм әрәм-шәрәм итү фактлары булды. 1943 нче елда финанс органнары болай смета-бюджет дисциплинасын бозу фактларына юл куймаска тиешләр. Дәүләт акчаларының һәрбер сумы, һәрбер тиене бары тик тиешле урынына гына тотылуын тәэмин итәргә кирәк.

1943 нче елда финанс эшенең барлык участоклары буенча да бөтен Союз күләмендәге социалистик ярышта беренчелекне яулап алу—Татарстан финанс работникларының сугышчан бурычы.

**Г. ХӘЙРУЛЛИН,**
ТАССР Финанс халык комиссары.

# СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

## 24 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

24 нче февральдә безнең гаскәрләр әлекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

23 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 5 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 150 гә якын автомашинаны юк иттеләр яки зарарладылар, 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар, 20 артиллерия һәм 8 миномет батареясының утын бастырдылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр һәм бер урында дошман оборонасын үтеп чыктылар. Немецлар, мотопехота һәм танклар китереп, авиация ярдәме белән, бик каты контратакалар ясадылар. Дошманның барлык контратакалары аның өчен зур югалтулар белән кире кайтарылды. 600 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында күп винтовкалар һәм автоматлар бар.

* * *

Краматорскаядан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Бер участокта немецларның танклары совет подразделениеләренең сугышчан сафлары арасына үтеп керә алганнар иде. Безнең сугышчылар, пулеметлардан атып, танклар артыннан килүче немецлар пехотасын танклардан аердылар һәм җиргә ятарга мәҗбүр иттеләр. Шул ук вакытта артиллеристлар һәм бронебойщиклар немецларның 13 танкысын юк иттеләр.

Харьковтан көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары, каты сугыш нәтиҗәсендә халык яши торган бер зур пунктны алдылар. Бу пункт урамнарында дошманның 200 дән артык үле гәүдәләре табылды. 6 орудие, бер ашлык складын һәм күп сугыш припаслары кулга төшерелде.

* * *

Малоархангельск районында халык яши торган зур пункт өчен булган сугышта Н-че часть 200 гә якын гитлерчыны юк итте. Икенче бер участокта безнең гаскәрләр, алга таба барып, трофейлар кулга төшерделәр. Шулар арасында 3 танк бар.

* * *

Краснодардан көнбатыштарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне дәвам иттереп, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта совет сугышчылары немецларның ике батальон пехотасын аердылар. Безнең подразделениеләр, немецларны тыгыз боҗра белән чолгап алып, корал ташлаудан баш тарткан гитлерчыларны юк итү өчен сугышлар алып баралар. Икенче бер участокта командиры иптәш Кислицын булган подразделениенең танклары, дошман тылына барып чыгып, ике ротага якын немец пехотасын юк иттеләр.

* * *

Февраль башында немецлар Белоруссиядә хәрәкәт итүче партизан отрядларының бер группасына каршы зур җәза экспедициясе җибәргәннәр. Партизаннар гитлерчыларның беренче атакасын кире кайтарганнар. Карательләр зур югалтуларга дучар ителгәннәр һәм кичкә таба чигенгәннәр. Төнлә белән партизаннар, тавышсыз гына часовойларны үтереп, гитлерчылар урнашкан авылга бәреп кергәннәр. Бик каты сугышта совет патриотлары 100 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырып ташлаганнар. Немецларның җәза отряды, бу көтелмәгән удардан айныганнан соң, партизаннарны куып бара башлаган. Совет патриотлары группасы урманга таба чигенгән һәм гитлерчыларны алдан әзерләп куелган засадаларга таба үз артыннан ияртеп килгән. Капкынга эләккән карательләр юк ителгәннәр.

* * *

Кызыл Армиянең 25 еллыгы турында Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказы илебездә гаять зур патриотлык күтәрелеше тудырды. Күп кеше катнашкан митингларда һәм җыелышларда хезмәт ияләре бер тавыштан болай дип белдерәләр:—иптәш Сталинның приказы безне ватанныбыз һәм совет коралы хакына яңа батырлыкларга рухландыра. Кызыл Армия моннан соң да барлык кирәкле нәрсәләрне алып торачак. Дошманны ватаныбыз чикләреннән кууны тизләтүдә батыр Кызыл Армиягә булышлык итү өчен без бөтенесен эшләрбез.

Ленинградта директоры иптәш Миронов булган заводта 35 ел эшләгән фрезеровщик иптәш Громов завод күләмендә булган митингта речь белән чыкты. Ул үзенең речендә болай диде: «Без, Ленин шәһәренең карт эшчеләре, иптәш Сталин приказын укып чыкканнан соң үзебездә яңа көчләр хис иттек. Кызыл Армиянең уңышлары безнең йөрәкләребезне шатлык һәм горурлык белән, явыз дошманны тәмам җимерергә һәм юк итәргә ныклы теләү белән тутыралар». Ленинградның Н-че завод эшчеләре митингысында, 1 нче Майга планнан тыш, бик күп оборона продукциясе эшләп чыгарырга йөкләмә алынды.

Пензада директоры иптәш Павлов булган заводның эшчеләр митингысында иптәш Ситникова речь сөйләде. Ул болай диде: «Иптәш Сталинның чакыруына без яңа стахановча эшләр белән җавап бирербез. Мин заводта моннан ярты ел элек, фронтка киткән иремә алмашка эшли башладым. Эшләп чыгарышны көн саен 200—250 процентка җиткерүне өстемә алам». Митингтан соң күп эшче хатын-кызлар үзләренең смена нормаларын арттырып үтәделәр.

Казахстан ССР, Җамбул районы, «Интимак» авыл хуҗалыгы артеле колхозчылары җыелышында колхозчы Сайбекова речь белән чыкты. Ул болай диде: «Верховный Баш Командующий иптәш Сталин приказын укып чыкканнан соң без үзебез өчен бер нәтиҗә ясыйбыз: ләгънәт төшкән немецларны тар-мар итүдә Кызыл Армиягә тырыш хезмәт белән бөтен көчебез белән булышырбыз. Быел без язгы чәчүне тагын да яхшырак үткәрербез һәм мул иген, дөге, чөгендер һәм яшелчә уңышы үстерербез». Колхозчылар фронтка үткән елга караганда 10.000 пот артыграк икмәк бирергә һәм шуның өстенә Кызыл Армия фондына 6 гектар җиргә бөртекле культуралар чәчәргә карар бирделәр.

# НЕМЕЦ-ФАШИСТ МОШЕННИКЛАРНЫҢ ЯЛГАН УЙДЫРМАСЫ

23 нче февральдә немецларның информация бюросы түбәндәге хәбәрне тапшырды: «Немецларның рәсми саннарына караганда, Кызыл Армиянең 5.400.000 кешесе плен төшкән. Шуның өстенә тагын үтерелгән һәм яраланган 12.800.000 кешене өстәргә кирәк. Шулай итеп, сугышның 20 ае эчендә Кызыл Армия 18.200.000 кешесен югалткан. Аннан соң, Кызыл Армия бу вакыт эчендә 48.000 орудие һәм 34.000 танк югалткан».

Немецларның бу «рәсми саннары» гитлерчыларның оятсыз уйдырмаларыннан башка бер нәрсә дә түгел. Моның кебек сафсатаны укып чыкканнан соң, акылы булган һәрбер кеше сорар: Германия информация бюросындагы жуликлар әйткән кадәр югалтуларга дучар булгач соңгы өч ай эчендә Кызыл Армия ничек итеп немец фашистлары армияләрен күп кенә җитди җиңелүләргә дучар итә алган соң, ничек итеп 14 өлкәне, крайны һәм автономияле республикаларны фашист басып алучылардан азат иткән соң, ничек итеп дошманның 112 дивизиясен тар-мар иткән, ничек итеп 700.000 нән артык дошман солдатларын һәм офицерларын юк итә алган, ничек итеп 300.000 нән артык кешене плен алган, ничек итеп немецларның 7.000 танкысын, 4.000 самолетын, 17.000 орудиесен һәм башка күп коралларын юк иткән яки кулга төшергән соң? Фашист шамакайларның үзләренең ялганнарында чиктән ашып киткәнлекләре һәм түшәмнән алынган саннар игълан иткәнлекләре ачык түгелме?

Немец-фашист кабахәтләренең ялган исәпләүләр техникасы күптән билгеле инде. Гитлерчылар йөзләрчә һәм йөзләрчә мең совет гражданнарын — русларны, украинлыларны, белорусларны, литвалыларны, латышларны, эстоннарны сугыш алып баруның барлык халыкара кагыйдәләренә каршы килеп, хәрби пленныйлар исәбенә кертеп, немецларга коллыкка, каторгага куып алып китәләр, аларны котылгысыз ачлыктан һәм газаплаудан үлемгә дучар итәләр. Алар вакытлыча оккупацияләнгән районнарда йөзләрчә һәм йөзләрчә мең совет кешеләрен кыралар, шул исәптән хатын-кызларны, балаларны һәм картларны үтерәләр һәм, үз җинаятьләренең эзләрен төрлечә яшерергә маташып, үзләре тарафыннан үтерелгән гражданнар халкын Кызыл Армиянең югалтулары исәбенә кертәләр.

Ләкин совет җирендә гитлерчыларның канлы җинаятьләре һәм сугышның барышы турында аларның оятсыз ялганнары гитлерчы кабахәтләрне котылгысыз үч алудан коткарып кала алмас.

**СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.**

# КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ 25 ЕЛЛЫГЫ УҢАЕ БЕЛӘН ЧИТ ИЛЛӘРНЕҢ ДӘҮЛӘТ, ХӘРБИ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕННӘН КОТЛАУЛАР

### РУЗВЕЛЬТНЫҢ КИҢӘШЧЕСЕ ҺӘМ МАХСУС ЯРДӘМЧЕСЕ ГАРРИ ГОПКИНСТАН

Бу сугышта Кызыл Армиянең уңышлары тарихта күренекле хәрби казанышларның берсе булып тора. Озак 18 ай буена Кызыл Армия тарихта гаять көчле хәрби басымга каршы үзенең сөекле ватанын саклады. Сталинград өчен мәңге истә калырлык сугышны тәмам иткәннән соң, ул, дошманны туктатып кына калмады, бәлки каршы һөҗүмгә башлады. Бу һөҗүм хәзерге вакытта Ленинградтан алып Кавказга кадәр булган барлык киң фронтта җәелеп бара. Үзенең җиңелмәслек ирләре, хатын-кызлары һәм оста җитәкчеләре белән Кызыл Армия Россиянең һәрбер ире һәм хатын-кызы тарафыннан гомуми тырышлыклар һәм ирекле корбаннар белән ярдәм алган бу армия котылгысыз рәвештә Гитлер көчләрен тар-мар итүгә нигез салды.

### ДӘҮЛӘТ СЕКРЕТАРЕ УРЫНБАСАРЫ УЭЛЛЕСТАН

Кызыл Армия төзелүгә 25 ел тулу уңае белән мин совет кораллы көчләренең гүзәл хәрби батырлыкларын күреп, һәрбер американы хис итә торган соклануны белдерү белән шатмын. Москваны, Ленинградны һәм Сталинградны искиткеч оборонадан соң тупас басып алучыларга каршы көрәштә бу армияләр һөҗүм сугышларында гаять зур җиңүләргә ирештеләр һәм ирешүдә дәвам итәләр. Аларның җиңүләре дөньяның күп өлешләрендә җир өстендә, диңгездә һәм һавада агрессия көчләренә каршы көрәш алып баручы берләшкән милләтләрнең көчләрен рухландыра торган гаять зур үрнәк бирәләр. Алар азатлык сөюче һәрбер ирне һәм хатын-кызны рухландыралар.

### ФИНАНС МИНИСТРЫ МОРГЕНТАУДАН

Сүзләрне азрак әйтү яхшырак була торган вакытлар булгалый. Хәзер шундый вакыт. Минем тарафтан язма формада әйтелгән теләсә нинди соклану Кызыл Армиянең героик казанышлары турында инде мәгълүм булганнарга нәрсәне булса да өсти алмас иде. Туган җирнең кар белән капланган салкын киңлекләрендә Кызыл Армия үзенең каны белән мәңгелек данын истә калдырды. Бөтен дөньядагы цивилизацияле кешеләр өчен өй, семья, ватан һәрвакыт иң кадерле нәрсә булып килде һәм ул кеше тормышына мәгънә бирә. Кызыл Армиянең рухландыручы үрнәге нәтиҗәсендә без американлылар, цивилизацияле бөтен дөнья халыклары кебек үк, тормышның чын мәгънәсен яхшырак аңлый башладык.

Болардан тыш түбәндәгеләр Советлар Союзына котлаулар белән мөрәҗәгать иттеләр: хәрби министр урынбасары Паттерсон, диңгез министры ярдәмчесе Бард, Вашингтон штатыннан сенатор-демократ Боун, вәкилләр палатасының хәрби эшләр комиссиясе председателе Мэй, медицина институты директоры профессор Сиджерист, драматург Лилиан Хэльман, Америка хезмәт федерациясе председателе Грин, производство профсоюзлары конгрессы председателе Мэррей, Флорида штатыннан сенатор-демократ Пеппер.

# *Милли театрның чәчәк атуы*

Шушы көннәрдә Казан шәһәрендә милли театрның эшенә багышланган конференция булып үтте. Конференциядә автономияле алты милли республиканың—Татарстан, Башкыртстан, Чувашстан, Удмуртия, Мордовия һәм Мари республикаларының делегатлары катнашты. Ватан сугышы көннәрендә мондый конференциянең чакырылуы үзе генә дә совет сәнгатенең актив иҗат тормышы белән яшәгәнлеген һәм үзенең культурасын сөя торган халыкның ихтыяры һәм рухы җиңелмәслек икәнлекне күрсәтә.

Конференциядә РСФСР Совнаркомы янындагы сәнгать эшләре идарәсе начальнигы иптәш Беспаловның «Ватан сугышы көннәрендә милли театрларның бурычлары турында», сәнгатьне өйрәнү фәннәре кандидаты иптәш Тоянның «Чирек гасыр эчендә милли театрлар төзелеше», профессор Григорьевның «Ватан сугышы көннәрендә совет драматургиясе» дигән темаларга докладлары һәм алты республика делегатларының информацияләре тыңланды

Совет власте елларында Советлар Союзы халыкларының театр сәнгате бик нык үсте. Октябрь революциясенә кадәр бездәге театрлар 9 телдә эшләгән булсалар, хәзерге көндә алар 50 милли телдә эшлиләр. Хәзерге көндә СССР да 410 профессиональ милли театр яшәп килә. Соңгы елларда төрле милли телләрдә күп кенә опералар һәм драма әсәрләре тудырылды. Иптәш Җиһановның татарча «Ильдар» операсы һәм иптәш Заимовның башкыртча «Акбузат» операсы милли театр сәнгате әсәрләре арасында күренекле урын тоталар. Беренче буларак, татарча «Шүрәле» һәм «Фатих» балетлары иҗат ителде. Яңа язылган драма әсәрләреннән «Хуҗа Насретдин», «Тукай», «Томан арты», «Кыю кызлар», «Ташкыннар» һәм башка әсәрләр тамашачылар тарафыннан яратып каралалар. Сугыш вакытында Нәкый Исәнбәтнең «Мәрьям», Тажи Гыйззәтнең «Таймасовлар семьясы», «Төнге сигнал» исемле әсәрләре һәм башка язучыларның күп кенә пьесалары барлыкка килде. Башкыртстанда «Ватан чакыра» һәм «Сүнмәс йөрәк», Чувашстанда «Баһадирлар», Мари республикасында «Шинельле кыз» исемле яңа әсәрләр язылды.

Шушындый уңышларга да карамастан, драматургия илебездәге тормышның бөтен ягын тирәнтен чолгап ала алганы юк әле. Театрлар алдында совет кешесе турында, фронттагы һәм тылдагы безнең геройларыбыз турында бик яхшы әсәрләр иҗат итү бурычы тора.

Сугыш көннәрендә фашизмга каршы көрәш фронтларында батырлыклар күрсәткән өчен татарлардан 2.883 кеше, башкыртлардан 450 кеше, марилардан 232 кеше, чувашлардан 263 кеше, удмуртлардан 246 кеше орденнар белән бүләкләнделәр. Безнең заманыбызның шушындый геройларын театр әсәрләрендә чагылдырырга кирәк. Совет сәнгате әнә шуңа омтыла.

Кадрларны сакларга, яшьләрне тәрбияләргә Татарстанда, Башкыртстанда һәм башка республикаларда яңа театр студияләре оештырырга, репертуарны киңәйтергә кирәк. Театр үзенең милли йөзен саклаган хәлдә репертуарын киңәйтергә тиеш.

Рус һәм Көнбатыш Европа классикларының иң яхшы әсәрләрен, шулай ук кардәш республикалардагы халыклар телендә язылган яхшы әсәрләрне төрле милли телләргә тәрҗемә итәргә, тәрҗемә әсәрләрнең сыйфат ягыннан иң югары дәрәҗәдә булуына ирешергә кирәк.

Конференция иҗат итү һәм оештыру ягыннан күп кенә мәсьәләләрне алга куйды. Бу мәсьәләләр буенча озак вакыт җитди эш алып барылырга тиеш.

**А. ДУБИНСКАЯ.**

Җаваплы редактор **И. ҮЗБЕКОВ.**

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность, транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ 1059 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 298